**Теләче районы Югары Кибәхуҗа урта мәктәбенең 90 еллык юбилееының тантаналы өлеше өчен сценарий**
**1 бүлек**

***Укучылар чыгышы ("Өйрәтәләр мәктәпләрдә" җырына бию) (1)***

*2 алып баручы алга чыга: (талгын гына көй яңгырый)*

**Гөлнар** Сагыш-сагынудан туган хисләр
Уятсалар кереп төшеңә
Дәрман алып, бер рухланыр өчен
Туган ягы кирәк кешегә.

Кайгы –хәсрәт төшсә иңнәреңә,
Эшләрең гел китсә кирегә.
Авыр чакта кайтып сыенырга
Туган ягы кирәк кешегә.

Бәхет елмаеп, шатлык килсә,
Ашлык өйсәң бөек көшелгә,
Шатлыкларны уртаклашыр өчен
Туган ягы кирәк кешегә.

Туган якта сулар һава гел саф,
Җилләре дә йомшак сирпелә.
Кендек каны тамган, тәпи баскан
Туган ягы кирәк кешегә.

**Зөлфәт** Хәерле көн, хөрмәтле авылдашлар, кадерле кунаклар! Кеше өчен иң изге сүзләр - әти-әни, туган як, мәктәп. Туган җиребезне сагынсак, туган йортыбыз, мәктәбебез күз алдына килеп баса. Мәктәпне уйласак туган җирне сагынабыз. Әлеге төшенчәләр кешенең йөрәк түрендә һәрчак янәшә булачак. Кая гына барып, кемнәр генә булсак та, без әти-әниебез, туган ягыбыз, туган мәктәбебез үстергән бала булып калачакбыз.

Бүген мәктәбебез үзенең 90 еллык юбилеен бәйрәм итә. Әйдәгез, бергәләп үткән юлларыбызны искә төшерик, сыйныфташларыбыз белән күрешик, бер-беребезгә, туган мәктәбебезгә изге теләкләребезне җиткерик! Мәктәп һәрбер кеше өчен иң изге, иң кадерле урын, шунлыктан чәчләребезгә чал керсә дә, үзебез инде өлкән яшьтә, арабызда әби-бабайлар булса да, һәркем аңа теләп кайта, ә туган мәктәп һәркемне сөенеп, көтеп каршы ала.

**Гөлнар** Бүгенге бәйрәм көне белән барчагызны да ихлас күңелдән котлыйбыз. Ерак араларны якын итеп килгәнегез өчен без сезгә чиксез рәхмәтле. Барыгызга да исәнлек-саулык, тынычлык-иминлек, аяз күк йөзе, гаиләләрегездә муллык, бәхет телибез.

**Бәйрәмебезне ачып җибәрү өчен сүзне районыбыз җитәкчесе , мәктәбебезнең 1984 елгы чыгарылыш укучысы Зарипов Илдус Фатиховичка бирик әле.**

**Яшь буынны тәрбияләүдә һәм укытуга керткән намуслы хезмәтләре өчен Теләче муниципаль районы администрациясенең Мактау грамоталары белән бүләкләнә:**
**мәктәп директоры - Миннекаева Гөлшат Гаптравефовна**
**Рус теле һәм әдәбияты укытучысы –Миннурова Мөнәвәрә Мәрдәновна.**

**Яшь буынны тәрбияләүдә һәм укытуга керткән намуслы хезмәтләре өчен Теләче муниципаль районы администрациясенең Рәхмәт хатлары белән бүләкләнә:**
**Өлкән тәрбияче – Гинатуллина Гөлчәчәк Наилевна**
**Өстәмә белем бирү педагогы - Галявиева Лилия Халиковна**

***"Тургай" ансамбле башкаруында җыр "Туган як турында"(2)***

**Зөлфәт** Һәрбер чорның үз матурлыгы бар. Кыш үзенең әче бураннары, чатнама суыклары белән. Яз - челтерәп аккан кар сулары, тезелешеп кайткан кыр казлары белән матур. Җәйнең йөзен аллы-гөлле чәчәкләр бизи. Ә көз? Көз. Алтын көз! Исеме дә әнә нинди матур яңгырый. Аның матурлыгы ил байлыгында, мул уңышында. Амбарлар икмәк, кешеләрнең күңеле нур, шатлык һәм горурлык белән тула. Һәм әлбәттә инде, мәктәбебезнең 90 еллык юбилееның тантаналы кичәсе дә нәкъ менә шушы көзге матур көнгә туры килде.
**Бүгенге бәйрәмебездә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасары Айрат Хәнәфиевич Зиннуров катнаша. Сүз сезгә бирелә Айрат Хәнәфиевич.**
**Гөлнар Мәгариф өлкәсендәге уңышлары өчен Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы белән бүләкләнәләр:**
**Химия, биология укытучысы – Ибраева Ризәлә Зәкиҗановна**
**Башлангыч сыйныф укытучысы – Каримуллина Мәүлия Махмутовна**
**Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының рәхмәт хаты белән бүләкләнәләр:**
**Математика укытучысы- Мифтахова Сәлимә Габдулловна**
**Башлангыч сыйныф укытучысы – Шогаепова Рания Рафиковна**
**Татар теле һәм әдәбияты укытучысы- Низаметдинова Вәсилә Әбелкарамовна**

***Татар халык биюе (кызлар) ("Чабата")(3)***

**Гөлнар**90 яшь тулды мәктәбемә
Зур юбилей! Узган зур гомер
Ничә буын синдә белем алган,
Чистартылган, агарган күңел.
Гасырга якын матур тарихың бар,
Шәкертләрең синең җитәрлек.
Арасында шундый зур шәхесләр,
Дан казанган, исең китәрлек.
Җиз кыңгырау моңы җыйды безне,
Таныш чыңы һаман колакта.
Бер мизгелгә вакыт туктап торчы,
Без кайттык бит тагын яшь чакка
**Зөлфәт Ә хәзер сүзне район мәгариф бүлеге башлыгы Гарипов Рөстәм Хәмитовичка бирәбез.**
**Зөлфәт Гомерләрен яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган ветеран укытучылар район мәгариф бүлегенең Рәхмәт хаты белән бүләкләнә.**

**Гөлнар** **Нуриева Галия Зариповна**
**Галявиева Гөлниса Габделхаковна**
**Хаҗиева Сания Гомәровна**
**Шәймарданова Флюра Әминовна**
**Нургалиев Габделбәр Миннәхмәтович**
**Нигъмәтҗанова Гәмбәрия Нуриевна**
**Шаһиев Хәниф Мансурович**
**Шаһиева Лена Хакимовна**
**Шәрәфиева Тәнзилә Шәрәфиевна**
**(Хисматова Фәймә Шәйхиевна)**

***Алия, Рания, Фәндүс җыр "Туган авылым*** " 4

**Гөлнар** Эх, балачак!
Мәктәбемә илтер юллар буйлап
Бала булып килә узасым.
Еллар үткәч килә:
-Исәнме! – дип
Балачакка кулым сузасым.
Эх, балачак үткән сукмаклардан
Яланаяк йөгереп үтәргә.
Бар дөньяны онытып, сабый булып.
Күбәләкләр куып китәргә.
Балачакта зурлар дөньясына
Сайлар өчен юллар җитәрлек.
Тик еракта калган сабый чакка
Тапмыйм юллар килеп китәрлек.
Тапмам микән, әгәр ул юлларны
Әкиятләрдән эзләп карасам.
Алар бармас микән үткәнемә,
Йомгакларым сүтеп карасам?

**Зөлфәт Сүзне мәктәбебез директоры Миннекаева Гөлшат Гаптрауфовнага бирәбез.**

***"Тургай" ансамбле" җыр "Кошлар кебек" 5***

**Зөлфәт** "Үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк," – дигән гыйбарә дә яши. Әйдәгез, без дә бераз үткәнебезгә күз салыйк әле.
Тарихи мәгълүматларга караганда, Югары Кибәхуҗа урта мәктәбенең тарихы ерак дәвергә 20 гасыр башына барып тоташа. Шул чорда ук инде җирле халык мәгърифәткә, дингә тартыла. Мәчет каршында балалар дин нигезләре белән бергә дөньяви фәннәрне дә өйрәнәләр. Башлангыч мәктәптән башта җиде, аннан сигезъеллык укуга күчәләр

1921 елда Югары Кибәхуҗа авылында башлангыч мәктәп ачыла. Анда беренче укытучы булып Максабаш авылыннан Мөбәрәк абый эшли башлый. Шулай ук бу мәктәптә Төрек-Тәмте авылы егете Габделхай үзен бик инициативалы укытучы итеп

таныта. Ул елларда көчле ачлык була, безнең яшь совет иленә Америка азык-төлек белән ярдәм итә. Габделхай олырак балалар белән бергә Арча станциясеннән азык алып кайтуда булыша.

Бу елларда башлангыч мәктәптә Олы Кибәхуҗа авылыннан Мостафин Марат та эшләп армиягә китә һәм Бөек Ватан сугышында һәлак була.

**Гөлнар** Сугыш елларында мәктәп мөдире булып Ракова Сара апа эшли.Ул елларда укытучы булып эшләгән кызлар - Талипова Таня, Садыкова Фатыймалар 1942 елның апрелендә үз теләкләре белән илне саклау өчен фронтка китәләр. Сара апаны РОНО мөдире итеп алгач, мәктәп мөдире итеп Зәйнуллина Галия билгеләнә. Бу чордагы укытучылар – Маннанова Хәдичә, Агачова Мария, Борһанова Кафия апалар балаларга белем бирүдә үзләренең көчләрен кызганмыйлар.

1948 елдан башлап мәктәп җидееллык , ә инде 1948 елларда сигезеллык итеп үзгәртелә. Бу чорда мәктәп мөдире булып Исламов Раиф Басырович эшли. Ул җитәкләгән коллектив укучыларга ныклы белем бирүгә бөтен көчен куеп эшли. 1967 елдан мәктәп - урта мәктәп итеп үзгәртелә. Аның җитәкчесе итеп Федоров Иван Федорович билгеләнә.

**Зөлфәт**Еллар үткән аккан сулар кебек,
Гомер генә кайтмас кирегә.
Тик балачак чакырып әйдәп торыр
Мәңге серле мәктәп иленә.

Мәктәп, мәктәп!.. Кем генә үзенең сабый чагын, балачагының бәхетле мизгелләрен сагынып искә алмый икән?! Кем генә үзенең тәүге укытучысы белән очрашулар көтеп яшәми икән?!

Менә шуларны истә тотып, без бүгенге бәйрәмебезгә төрле елларда Югары Кибәхуҗа урта мәктәбендә белем алган, хәзерге вакытта илебезнең төрле төбәкләрендә гомер итүче, төрле өлкәләрдә зур дәрәҗәләргә ирешкән сабакташларны чакырдык. Без аларны, бер мизгелгә генә булса да, тормыш мәшәкатьләреннән арынып, мәктәп сукмагы аша үтәргә дәшәбез.

**Гөлнар** ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, композитор, мәктәбебезнең 1963 елгы чыгарылыш укучысы Хатыйпов Фәрит Хәнәфи улына бирәсебез сүз. Рәхим итегез Фәрит абый. ( *Хатыйпов Фәрит абыйга сүз бирелә)*

_ **Зөлфәт**1969-1979 елларда мәктәп мөдире булып Шагиев Хәниф Мансурович эшли.Ул елларда Никитина Екатерина, Газизова Галия, Борһанова Кафия, Әхмәтгалиева Фәүзияләр укучыларга ныклы белем бирәләр. 1969 елда урта мктәпнең беренче чыгарылышын 21 кеше тәмамлый.

**Гөлнар** Хәниф Мансурович идарә иткән чор - мәктәп тарихында бик тә җаваплы этап , мәктәпнең барлык балаларга да гомуми урта белем белем бирә башлау чоры, яңа көчле кадрлар белән тулылану вакыты, кечке мәктәпләр гөрләп эшләгән вакыт һәм киләчәктә төпле белем бирү өчен ныклы фундамент әзерләнү чоры.

Хәниф Мансурович, истәлекләрегез белән безнең белән дә уртаклашсагыз иде. *(Сүз Хәниф Мансуровичка бирелә)*

**Зөлфәт**Ни белән үлчәнә гомер?
Калган эзләр белән.
Кеше күңеленә орлык итеп
Салган сүзләр белән.

Үзенең хезмәт юлында дистәләрчә Мактау грамоталары, "Халык мәгарифе отличнигы" күкрәк билгесе һәм башка күптөрле бүләкләргә ия булган Шаймарданова Флера Әминовна. Эш дәверендә балаларга белем һәм тәрбия бирүдә көчен кызганмыйча эшләүче фидакарь педагог булдыгыз. Сәхнәбез түренә сезне чакырабыз, рәхим итегез Флера Әминовна. *(Шаймарданова Ф.А. сүз бирелә)*

**Гөлнар** Мәктәп еллары!
Нинди гүзәл көннәр!
Тупланганнар анда барсы да**:**
Укучының кайгы-шатлыклары,
Яшь кызларның йөрәк сагышы…
Шау-гөр килеп узган кичәләр,
Яшьләрнең шат,шаян җырлары,
Яшь кызларның керсез хыяллары,
Җырлап үткән мәктәп еллары.
Синдә калды, барысы синдә калды
Гүзәл уку, мәктәп еллары.

Сүзебезне филология фәннәре докторы, КФУ журналистика факультеты деканы, мәктәбебезнең 1978 елгы чыгарылыш укучысы Гарифуллин Васыйл Заһит улына бирик әле. Туган мәктәбегез турында истәлекләрегез белән уртаклашсагыз иде. *(Гарифуллин В.З. сүз бирелә)*

**Зөлфәт**Кеше гомере мәктәп аша.
Моңлы бер җыр кебек сузыла.
Белем сукмакларын яра-яра
Киләчәккә юлы сызыла.

1970 еллар укучысы, химия фәннәре докторы, КТУ доценты,ТР ның атказанган тренеры, Татарча көрәш федерациясенең президиум әгъзасы,АКШ президенты гранты иясе Кадыров Марсель Каһирович, сезне сәхнәбез түренә чакырабыз , рәхим итегез. *(Кадыров М.К. ка сүз бирелә)*

**Гөлнар** 1980-1982 елларда Зиннуров Шамил Зиннур улы җитәкчелек итә. Шамиль Зиннурович инициативасы белән Максабашта һәм Ю. Кибәхуҗа авылларында кичке мәктәп эшли башлый. *(Илдус Фатыхович Зөлфәтне котлый)*
1983- 1995 елларда мәктәп директоры булып Нургалиев Габделбәр Миннәхмәтович эшли. Ул җитәкчелек иткән чорда мәктәптә халык мәгарифе алдында торган бурычларны хәл итүдә лаеклы өлеш кертелә. 1988 елда бөтен мөмкинлекләре булган яңа мәктәп кулланугa тапшырыла.
1980-1987 елларда мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшләгән Садыйков Равил Хасановичка бирик әле, рәхим итегез. *(Садыков Р.Х. бирелә)*

**Зөлфәт** Кешеләргә шәфкать, көч өләшеп,
Еллар узган, күпме таң аткан.
Туганда ук, табигать үк Сезне,
Ахры, укытучы итеп яраткан!..

Әйе, бу сүзләр турыдан туры бөтен гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган, ветеран укытучыбыз, халык мәгарифе отличнигы, Татарстанның атказанган укытучысы, Максабаш башлангыч мәктәбе директоры булып эшләгән Тәнзилә апа Шәрәфиевага кагыла.
Үзегезнең истәлекләрегез белән безнең белән дә уртаклашсагыз иде. Рәхим итегез.
*(Шарафиева Т.Ш. сүз бирелә)*

***<u>Татар халык биюе (парлы) 6</u>***

**Гөлнар** Бусагаңны атлап керү белән,
Әлифбадан хәреф өйрәндем.
Ишеттерде синең ярдәмеңдә
Үз тавышын илгә йөрәгем.
И мәктәбем, күңел җырым аша
Җитсен сиңа олы рәхмәтем.
Мин һаман да укучысы әле
Тормыш дигән олы мәктәпнең.

Бүгенге кичәбездә мәктәпне алтын һәм көмеш медальләргә тәмамлаган укучыларыбыз да катнаша.
Ахметгалимов Резил Исламович, Гарифуллин Васил Заһитович, Салихова Вәсимә Мансуровна, Низамова Әлфинә Ягъфәровна, Низамова Ләйсән Фәукатовна, Хасанова Эльвира Рамилевна, Миннекаева Гөлнар Ринатовна, Низамова Чулпан Фәукатовна.

**Зөлфәт** Һәр төбәк үзенең данлыклы уллары, кызлары белән горурлана. Төбәккә бәяне дә шуннан чыккан күренекле кешеләрнең дәрәҗәсенә карап бирәләр. Авылыбызның данлыклы тарихы, күренекле,бөек, мактаулы исемнәр алган мөхтәрәм кешеләре бихисап. Аларның һәрберсе – зур тарихлы Югары Кибәхуҗа мәктәбен тәмамлаган шәхесләр. Бүгенге бәйрәмдә аларның барысын да атап китеп булмаса да, кайберләрен искә алып үтми мөмкин түгел.
Теләче муниципаль районы хакимияте башлыгы Зарипов Илдус Фатыйхович, Низаметдинов Ралиф Хәнифович, Гарифуллин Васыйл Заһитович, Кадыйров Марсель Каһирович, Галявиев Шамил Шәйхиевич, Ахметханов Җәүдәт Йосыпович, Касыймов Әдһәм Нәҗипович, Зиннатов Вәкил Гарифуллович, Зиннатов Фәргать Гарифуллович, Ихсанов Вазыйх Вагыйзович, Нургалиев Искәндәр Габделбәрович, Галиев Роберт Тимерханович, Хатыйпов Фәрит Хәнәфиевич, Низамов Рәсим Мөхәммәтович, Сафиуллина Алинә Васыйловна Югары Кибәхуҗа урта мәктәбендә укыганнар.

***<u>Гильмутдинов Илдус җыр “Күрешербез әле” 7</u>***

***(Өчесе бергә чыга: Фаил, Зөлфәт, Гөлнар)***

**Гөлнар** Әй, мәктәп, мәктәбем! Кем генә моңлы кыңгырау тавышын сагынып кабат сиңа килми дә, кем генә үткән балачагының бәхетле мизгелләрен, яраткан укытучыларын юксынмый икән?! Мәктәбемә илтер юллар буйлап, Бала булып килә узасым. Еллар үткәч килә: -Исәнме! – дип, Балачакка кулым сузасым.

**Зөлфәт** Әй мәктәбем, изге белем йорты,
Балачакнын гүзәл бишеге.
Зур дөньяга алып чыккан юлга
Озатучы тәүге ишегем.

Кайда гына хезмәт куймый бүген,
Син озаткан газиз балалар.
Алар мәңге синең мәктәбенең
Укучысы булып калалар.

Киң дөньяга таралышкан меңнәр,
Очар коштай канат кагынып.
Синдә канат ярган балаларың,
Яши һаман сине сагынып.

**Исламов Фаил** *(5 кл.укучысы)* Хөрмәтле абыйлар, апалар!
Мин сезнең белән олы юбилейда очраша алуыма бик шат. Бүген сез кабатланмас Балачак илендә кунакта булдыгыз. Минем тизрәк үсәсем, олы кеше буласым килә иде. Сез минем фикерләремне үзгәрттегез. Балачак – иң бәхетле чор икән бит.
Без сезнең уңышларны күреп сокланабыз. Тормышта үз юлыңны табар, югалып калмас өчен безгә әле бик нык тырышырга кирәк икән. Бүгенге очрашу безгә көч өстәде.
Без сезнең алда тырышып укырга, укытучыларыбызның, мәктәбебезнең данын төшермәскә , лаеклы алмаш булып үсәргә сүз бирәбез.
Сезне мәктәпнең 100 еллык юбилееында көтеп калабыз.

**Гөлнар** Хөрмәтле авылдашлар, бәйрәмебез кунаклары! Югары Кибәхуҗа урта мәктәбенең 90 еллыгына багышланган кичәбезнең беренче бүлеге ахырына якынлашып килә. Тәнәфестән соң барыгызны да кичәбезнең икенче бүлеге – зур концертка чакырабыз. Безне хөрмәт итеп килүегез өчен барыгызга да зур рәхмәт! Без сезгә сәламәтлек, озын гомер, җан тынычлыгы теләп калабыз.

***Татар халык биюе 8***